# КАРАР

28 ноябрь 2020 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы җирлегендә Байлангар авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 25.11.2020 елда 10.00 һәм 14.00 сәгатьтә үткәрелгән түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы, Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Байлангар авылында Ф. Заһидуллин, Мәктәп урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байлангар авылында, вак таш җәеп, Ф. Заһидуллин, Г. Тукай, Мәктәп урамнарында юллардагы чокырларны ямау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Совет урамы, 27 нче торак йорт һәм Совет урамы, 69 нчы торак йорт янында Нурминкә елгасы аша салынган җәяүлеләр өчен култыксалы/рәшәткәле күперне төзекләндерү,(материал сатып алу; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;)

- Байлангар авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;

-Байлангар авылы зиратына материал сатып алу һәм коймалар урнаштыру(проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

- Байлангар авылы урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, җәен авыл территориясен чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр

сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Байлангар авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- Байлангар авыл зиратына кышкы чорда кабер казу өчен генератор һәм вата торган чүкеч сатып алу;

- Байлангар авылында Совет урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру

- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү өчен бензин пычкысы һәм бензокосилкасы сатып алу;

- Байлангар авылында Сабантуй үткәрү өчен территорияне төзекләндерү ,материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган , җыенда катнашучылар исемлегенә, 551 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 292

Тавыш бирүнә нәиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 292 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2.Сорау буенча карарны танырга: «2021 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы , Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булганнар әниләр ,80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2021 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Байлангар авылында Ф. Заһидуллин, Мәктәп урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байлангар авылында, вак таш җәеп, Ф. Заһидуллин, Г. Тукай, Мәктәп урамнарында юллардагы чокырларны ямау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Байлангар авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;

- Байлангар авылы зиратына материал сатып алу һәм коймалар урнаштыру;(проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;)

- Байлангар авылы урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, җәен авыл территориясен чабу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байлангар авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- Байлангар авыл зиратына кышкы чорда кабер казу өчен генератор һәм вата торган чүкеч сатып алу;

- Байлангар авылында Совет урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру

- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү өчен бензин пычкысы һәм бензокосилкасы сатып алу;

- Байлангар авылында Сабантуй үткәрү өчен территорияне төзекләндерү ,материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы И.Х.Минегалиев